КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 декабрь г.Казань № 1161

«Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында мохтаҗ йөкле хатын-кызларны өзлексез глюкоза мониторингы системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклау системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында мохтаҗ йөкле хатын-кызларны өзлексез глюкоза мониторингы системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 19 декабрь, 1161 нче
карары белән расланды

«Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында мохтаҗ йөкле хатын-кызларны өзлексез глюкоза мониторингы системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Шикәр диабетына каршы көрәш» федераль проекты кысаларында мохтаҗ йөкле хатын-кызларны өзлексез глюкоза мониторингы системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында йөклелек буенча диспансер исәбендә торучы 1 типтагы шикәр диабетлы, 2 типтагы шикәр диабетлы, шикәр диабетының моноген формалы һәм гестацион шикәр диабетлы йөкле хатын-кызларны «Шикәр диабеты белән көрәш» федераль проекты кысаларында «акушерлык һәм гинекология» һәм «эндокринология» юнәлешләре буенча медицина ярдәме стандартлары һәм клиник тәкъдимнамәләр нигезендә глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм Татарстан Республикасы бюджетына әлеге максатлар өчен федераль бюджеттан бирелә торган субсидия (алга таба – субсидия) (алга таба – шул ук эзлеклелектә шикәр диабетлы йөкле хатын-кызлар, гестацион шикәр диабетлы йөкле хатын-кызлар, бюджеты акчасы) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Бюджет акчасы, глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларының тенологик сыйфатнамәләре эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларына өстенлек бирелүне исәпкә алып, шикәр диабетлы йөкле хатын-кызларны, гестацион шикәр диабетлы йөкле хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итүгә җибәрелә.

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Бюджет акчасын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, иң чик финанслау күләмнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң,иң чик финанслау күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарына таянып, әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

глюкозаны өзлексез мониторинглау системаларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә.

Шикәр диабетлы йөкле хатын-кызларны һәм гестацион шикәр диабетлы йөкле хатын-кызларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү табиблар рецептлары буенча даруханә оешмалары аша гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисаплылык, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык урнаштыра.

8. Бюджет акчасын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап бирелә.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына субсидиянең калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.